МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 150/о

П Р И К А З　　　　Б О Е Р Ы К

«07» 11 2022

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына кергән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе турында

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына кергән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.
2. Юридик бүлеккә (Э.Ю.Латыйпова), дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.
3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына (Р.Ж.Зәйнуллинага) бу боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәлгән вакыттан башлап 10 көн эчендә аның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.
4. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр　　　　М.М.Айзатуллин

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «_07_»__11__2022 ел, №150/о боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына кергән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында (алга таба – Министрлык) коррупция һәм ришвәтчелек фактлары, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен чикләү, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу турында белешмәләрне үз эченә алган коррупция юнәлешендәге фактлар буенча, шулай ук Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – хезмәткәрләр) тарафыннан, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булып тормаган вазыйфаларны били торган һәм Министрлыкта эшчәнлекне техник яктан тәэмин итү һәм хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыра торган эшчеләр (алга таба – эшчеләр) тарафыннан кылынган, хезмәт хәленнән явызларча файдалану билгеләрен үз эченә алган башка гамәлләр турында гражданнардан алынган мөрәҗәгатьләрне (алга таба – мөрәҗәгать) карау үзенчәлекләрен билгели.

Министрлык хезмәткәрләре һәм эшчеләре булып тормаган затларга кагылышлы коррупция юнәлешендәге фактлар турында белешмәләр булган мөрәҗәгатьләр «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль законның 8 статьясындагы 3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итәргә вәкаләтле булган, тиешле органга яисә тиешле вазыйфаи затка җибәрелергә тиеш.

Мөрәҗәгатьтә әзерләнә, кылына яки кылынган хокукка каршы гамәл, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында белешмәләр булган очракта, мөрәҗәгать, компетенцияләренә туры китереп, мөрәҗәгатьне Министрлыкта теркәгән көннән соң өч көн эчендә, кирәк булганда – кичекмәстән, хокук саклау органнарына җибәрелергә тиеш.

2. Министрлыкка кергән мөрәҗәгать «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда теркәлә һәм карала.

3. Дәүләт хезмәте һәм кадр бүлеге тарафыннан билгеләнгән тәртиптә хезмәткәргә (эшчегә) карата хезмәт тикшерүе үткәрелә башлый. Хезмәткәрдән

(эшчедән) алынган мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар буенча язма аңлатмалар алына.

4. Хезмәт тикшерүе нәтиҗәләре буенча бәяләмә нигезендә коррупция чагылышлары билгеләре булуы турында мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар расланган очракта, министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) әлеге бәяләмәне алган көннән алып өч эш көне эчендә Министрлыкның дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясендә материалларны карау турында карар кабул итә.

5. Хезмәткәргә (эшчегә) карата тиешле фактлар расланган очракта, җыелган материалларны анализлаудан һәм аның язма аңлатмаларыннан чыгып, Министрлыкның дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышы беркетмәсенә кул куелганнан соң 10 көн эчендә аңа Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану турында боерык чыгарыла.

Хезмәт тикшерүе нәтиҗәләре буенча әзерләнә, кылына торган яисә кылынган законга каршы гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында билгеле булган очракта, тиешле мәгълүмат компетенцияләре нигезендә хокук саклау органнарына – хезмәт тикшерүе тәмамланган көннән башлап өч көн дәвамында, ә кирәк булганда, кичекмәстән дә җибәрелергә тиеш.

6. Мөрәҗәгатьне юллаган гражданинга җавап әзерләү Министрлыкта коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча җаваплы зат (алга таба – җаваплы зат) тарафыннан башкарыла.

Мөрәҗәгатьне карауда катнашучы затлар гражданинга җавап җибәрү вакыты узып киткәнче 15 көннән дә соңга калмыйча, җаваплы затка язмача мөрәҗәгать буенча үз тәкъдимнәрен җибәрәләр.

7. Әгәр мөрәҗәгатьтә җаваплы затка карата коррупция юнәлешендәге фактлар турында белешмәләр булса, соңгысы аны карап тикшерүдә катнашмый, үз ризалыгы белән катнашудан баш тарта. Мондый мөрәҗәгатьне карау дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге, шулай ук Министрлыкның юридик бүлеге тарафыннан башкарыла.